**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

30.06.2017 № 404

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль подсистемалары идарә органнары һәм көчләре өчен югары дәрәҗәдә әзерлек режимын кертү турында**

Начар һава шартлары комплексы нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмау максатларында, «Халыкны һәм территорияләрне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль подсистемалары идарә органнары һәм көчләре өчен 2017 елның 1 июленнән 2017 елның 2 июленә кадәр (бу көнне кертеп) югары дәрәҗәдә әзерлек режимын кертергә һәм төбәк (муниципальара) дәрәҗәсендә эшчәнлек алып барыла дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

югары дәрәҗәдә әзерлек режимында эшләгәндә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль подсистемалары идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеген координацияләүне;

әлеге боерыкны үтәгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары гамәлләрен килештерүне.

3. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ